# КАРАР

**“15” ноябрь 2022 ел** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 15 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 350 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 700 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- Чапаев урамының 1 йортыннан 39 йортына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау;
- В. Әһлиуллин, Чапаев, Нагорная урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю;
- 2 данә күләмендә янгын краны сатып алу һәм урнаштыру;
- янгын гидрантларына, краннарына комплектлау җиһазлары сатып алу (3 данә күләмендә янгын сүндерү өчен җиң);
- Пөшәңгәр авылында су челтәрләрен ремонтлау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

Халык җыены йомгаклау беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 276 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 144 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар

тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 144 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «2023 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Пөшәңгәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 350 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 700 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- Чапаев урамының 1 йортыннан 39 йортына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау;

- В. Әһлиуллин, Чапаев, Нагорная урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю;

- 2 данә күләмендә янгын краны сатып алу һәм урнаштыру;

- янгын гидрантларына, краннарына комплектлау җиһазлары сатып алу (3 данә күләмендә янгын сүндерү өчен җиң);

- Пөшәңгәр авылында су челтәрләрен ремонтлау;

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 33 йорт, Чапаев урамы, 42А йорты адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов